КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 август г.Казань № 645

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының кайбер нигезләмәләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары белән расланган Төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибенең 2, 6 һәм 7 пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 ел, 29 октябрь, 1015 нче карарының 17 пунктындагы икенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары белән расланган Төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләш-терелергә тиешле җир кишәрлекләренә

кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 15 ноябрь, 1012 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин